*Муниципаль тур*

**Татар гомуми белем бирү оешмаларында укучы балалар өчен татар теленнән республика олимпиадасының муниципаль туры биремнәре 2023-2024 нче уку елы 7 нче сыйныф**

**Үткәрү вакыты – 150 минут**
**Максималь балл – 55**

## I. Тест биремнәрен эшләгез.

1. Киң әйтелешле [о] авазы булган сүзне билгеләгез. **(2 балл)**
1) торна
2) торт
3) тояк
4) торма

2. Җөмләдә кече тел тартыгы кулланылган сүзне билгеләгез. **(2 балл)**
*Мәгърифәт өстәр, иренмәс һич кеше булган кеше (Г. Тукай)*
1) мәгърифәт
2) өстәр
3) иренмәс
4) кеше

3. *көмеш* сүзе күчерелмә мәгънәдә кулланылган рәтне билгеләгез. (**2 балл**)
1) көмеш кашык
2) көмеш алка
3) көмеш беләзек
4) көмеш тамчы

4. Бирелгән мәгънәгә туры килә торган сүзне билгеләгез. **(2 балл)**
*Киемнәрне пычранудан саклар өчен алга киелә яки билгә бәйләп куела торган япма*
1) күлмәк
2) камзул
3) алъяпкыч
4) бишмәт

5. Фразеологизмның мәгънәсен билгеләгез. **(2 балл)**
*Кочак җәеп*
1) тиз генә

2) шатланып

3) киң күңелле

4) ачуланып

6. Мәкальнең дәвамын дөрес билгеләгез. **(2 балл)**

*Акыллы өйрәнер,*

1) күп белем алыр.
2) еракка китәр.
3) ахмак өйрәтер.
4) тиз аңлар.

7. Әйтү максаты ягыннан тойгылы җөмләне билгеләгез. **(2 балл)**

1) Алар бүген дәрескә соңга калдылар.
2) Бүген сез дәрестән соң кинога барасызмы?
3) Күрегезче, нинди матурлык!
4) Озын караңгы төннәр башланды.

8. Иялек килешендәге исем кулланылган мәкальне билгеләгез. **(2 балл)**

1) Кыюлык – адәмнең канаты.
2) Кеше күңеле – караңгы төн.
3) Картлар сүзен кар басмас.
4) Тәвәккәллек көч бирә.

9. Җөмләдәге нокталар урынына тиешле тыныш билгесен билгеләгез. **(2 балл)**

*Икмәк сүзе .... ана исеме белән янәшә торырлык олы сүз.*

1) өтер

2) өндәү

3) нокта

4) сызык

10. Җөмләдәге тәмамлыкны билгеләгез. **(2 балл)**

*Алсу шигырьне дәрестә кычкырып сөйләде.*

1) Алсу

2) шигырьне

3) дәрестә

4) сөйләде

## II. Теоретик бирем.

Хәбәр турында языгыз. Фикерегезне мисаллар белән дәлилләгез. (**5 балл**)

## III. Уйлагыз һәм җавапларны языгыз.

1. Алмашлыклар һәм аларның төркемчәләрен тәңгәлләштерегез, җавапны саннар белән языгыз. **(5 балл)**

| | |
|---|---|
| А) берәү | 1) зат алмашлыгы |
| Ә) һич | 2) билгеләү алмашлыгы |
| Б) һәр | 3) сорау алмашлыгы |
| В) нәрсә | 4) билгесезлек алмашлыгы |
| Г) миңа | 5) юклык алмашлыгы |

**Җавап : ________________________**

## IV. Гамәли-иҗади бирем.

1. Җәя эчендәге сүзләрнең дөресен сайлап, астына сызыгыз. **(4 балл)**

Сәгать алты тулар-тулмас иртәнге прогулкага чыгып барганда, күрше фатирга звонок биреп торучы карчыкка (күзем төште / йөзем борылды / күзем бактым). Звонок (урыны / төймәсе / ноктасы) шактый биектә, ә әбинең буе тәбәнәк кенә: ул, аяк очларына басып, өскә үрелгән. Язгы пальто өстеннән (кунган / бөркәнгән / җәелгән) ак шәле җилкәсенә җыерылып төшкән. Карчык, кулын звонок төймәсеннән алмый гына, миңа текәлеп карап куйды. Йөзе борчулы, күз карашында ниндидер өметсезлек, аптыраш сизелә иде. Болай да ябык, җыйнак гәүдәсе ниндидер борчудан (аптырап / куырылып / ямьшәеп) калган кебек күренә. (*Р. Хафизовадан*)

2. Шигырьне укыгыз һәм күп нокталар урынына тиешле хәрефләрне куегыз. **(2 балл)**

Кыр казлары, кая очасыз сез?
Берегез алда, берегез артта сез.
Кыйгылдашып, сез нәрсәне болай,
Күмәкләшеп, җигелеп тартасыз?
Беләм, беләм, җәйне тартасыз сез
Чинар үскән диңгез бу...на,
Магнолиял...р үскән бакчаларга,
Йөз...м үскән та...лар куенына. (*Ә. Фәйзи*)

3. Шигырьдән антоним сүзләрне күчереп языгыз. (**2 балл**)

____________________________________________________

4. Рус теле аша кергән Европа алынмасын күчереп языгыз. (**2 балл**)

____________________________________________________

5. *Бакчаларга* сүзен мәгънәле кисәкләргә аерып языгыз, шартлы билгеләр белән күрсәтегез, морфологик анализ языгыз. **(4 балл)**

______________________________________________________________________

6. Ирен гармониясенә буйсынган сүзне күчереп алыгыз. **(2 балл)**

______________________________________________________________________

7. “Кышкы табигатьтә” темасына 8-9 җөмләдән торган инша языгыз. (**9 балл**)